СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

25.01.2021 | с. Коргуза | 5-34

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне юкка чыгару хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019нчы елның 16нчы декабреннән 432-ФЗ Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2017нче елның 27нче сентябрендәге 30-133нче номерлы карары белән расланган Нигезләмәне гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С.А.Сакин